| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кошман ав. № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 25 ноябренә 14 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 31 йорт адресы буенча урнашкан Кошман төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 25 ноябренә 15 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 39 йорт адресы буенча урнашкан Кошман балалар бакчасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2024 елның 26 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2024 елның 27 ноябренә 17 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2024 елның 29 ноябренә 11 сәг 00 минутка Кошман авылы, Тукай ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. 2024 елның 29 ноябренә 13 сәг 00 минутка Кошман авылы, Сәгыйди ур, 58 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын билгеләргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кошман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән авария хәлендәге агачларны кисү һәм чыгару, территорияне чабу, балалар мәйданчыгы урнаштыру)
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина